| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.04.2024 Казан ш № 263

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 12.07.2018 №550, 10.09.2018 №842, 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1040, 15.05.2020 №297, 20.07.2020 №521, 28.09.2020 №675, 07.06.2021 №403, 19.10.2021 №770, 16.06.2022 №554, 29.08.2022 №813, 14.11.2022 №1000, 20.06.2023 №475, 16.02.2024

№110 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 15.04.2024
елның 263 номерлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.3.1 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) укытуга юллама (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның рәвешләрен раслау турында» 2024 елның 30 гыйнварындагы 32н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча);»;

2.4.5 пунктта:

беренче абзацта «Инвалидларның федераль реестры» (алга таба – ИФР) федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» (алга таба – БЦП) дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләре белән, «ИФР белешмәләр» сүзләрен «БЦП белешмәләр» сүзләре белән алмаштырырга;

икенче абзацта «ИФР инвалидлык турында белешмәләр» сүзләрен «БЦП инвалидлык турында белешмәләр» сүзләре белән алмаштырырга, «ИФР аша ведомствоара сорату» сүзләрен «БЦП аша ведомствоара сорату» сүзләре белән алмаштырырга;

өченче абзацта «ИФР белешмәләр» сүзләрен «БЦП белешмәләр» сүзләре белән алмаштырырга;

2.5 пунктта «2.5. Татарстан Республикасы порталында, Бердәм порталда, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр урнаштырылган:» сүзләрен түбәндәге сүзләр белән алмаштырырга: «2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр Татарстан Республикасы порталында, Бердәм порталда, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган:»;

2.6.6 пунктның җиденче абзацында «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләре белән алмаштырырга.